**КАРАР**

**26 ноябрь 2020 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, җыен 25 ноябрь 2020 елда утте:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Лесная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- Хасановка авылындагы урам юл челтәрен тоту

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 5 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогында халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa

2. 2021 елда үзара салым суммасын 7000 сумга кадәр арттырырга, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Өркеш авыл җирлегенең Хасановка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә:

- Лесная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- Хасановка авылындагы урам юл челтәрен тоту;

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Өркеш авыл җирлеге башлыгы А.Ш.Әгләмова